Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы карары

2022 елның 29 августы № 64

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 85 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 12 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар (алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар) әлеге статьяның 3.1 һәм 3.2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.

2) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.2 пунктчасын өстәргә:

«3.2. Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, шәһәр округының генераль планы бер яисә берничә торак пункт территориясенә карата, аларның өлешләре буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә уздырыла. Бу очракта җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы бер айдан артык була алмый".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе Э.И.Байдамшин